**Рус телендә урта гомуми белем бирү мәктәбенең рус төркемендә укучылар өчен татар теленнән үткәрелә торган муниципаль тур өчен олимпиада биремнәренә җаваплар 2018-2019 уку елы, 4 нче сыйныф**

**Ответы на олимпиадные задания муниципального тура по татарскому языку для общеобразовательных организаций с обучением на русском языке (для изучающих татарский язык) 2018-2019 учебный год, 4 класс**

*Максимальный балл – 75*

*Время выполнения – 90 минут*

***Письменная часть***

**1. Образуйте сложные слова, соединив два слова в одно.** *(6 баллов)*

АШ, ТАШ, БОДАЙ, КУЛ, ТӨН, КОШ, БАКА, ЯУЛЫК, ЯК, КАРА, АК, ХАНӘ

| | |
|---|---|
| ТАШБАКА | КАРАБОДАЙ |
| ТӨНЬЯК | КУЛЪЯУЛЫК |
| АККОШ | АШХАНӘ |

**2. Напишите вопросы, ответами на которые являются следующие предложения.** *(12 баллов)*

1) – **Абдулла Алишның нинди әсәрләрен яратасың?**

– Мин аның “Нечкәбил”, “Куян кызы” әкиятләрен бик яратам.

2) **– Өегездә татар халкының нинди милли ризыкларын пешерәсез?**

– Без өйдә өчпочмак, бәлеш, чәк-чәк пешерәбез.

3) **– Нишләп бик тәмле соң бу бәлеш?**

– Аны бит әнием пешерде, шуңа күрә бик тәмле!

4) **– Ник елыйсың, берәр җирең авыртамы әллә?**

– Юк, күз яшьләре шатлыктан да агалар бит алар...

*(Җаваплар якынча бирелде.)*

**3. Раставьте предложения в нужном порядке, чтобы получился связной текст (укажите последовательность в цифрах).** *(10 баллов)*

| № | Предложения | Макс. кол-во баллов – 10 | Баллы |
|---|---|---|---|
| 2 | Үзе кечкенә булса да, тавышы бик еракларга ишетелгән, ди. | 1 | |
| 4 | Шулай беркөнне су астыннан өскә күтәрелгән бу бака һәм тирә-якны яңгыратып бакылдарга керешкән. | 1 | |
| 6 | Үрдәк баканың бакылдавын мактарга тотынган. | 1 | |
| 9 | Бака үрдәкнең борынына менеп атланган. | 1 | |
| 1 | Түгәрәк күл буенда, камышлыклар төбендә яшәгән, ди, бер бакылдык бака. | 1 | |
| 7 | Бака бик шатланган, тагын да күбрәк бакылдаган. | 1 | |
| 5 | Шулвакыт камышлар арасында йөзеп йөргән үрдәк, баканың тавышын ишетеп, аның янына ашыккан. | 1 | |
| 3 | Ул көн-төн мактанган: «Бакка-как-как, мине эзләп тап! Миннән оста җырчы, биюче юк. Исемем — Бакылдык, үзем бер батам, бер калкам»,— ди икән. | 1 | |
| 8 | «Кил әле, борыным өстенә мен әле. | 1 | |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | Колакларым катырак, җырыңны бик ишетәсем килә»,— дигән үрдәк. Бака бик шатланган. | | |
| 10 | Җырларга дип авызын ачуы булган — үрдәк баканы капкан да йоткан. | 1 | |

**4. Являются ли данные высказывания верными? Поставь знак «+» или «-» в соответствующей ячейке в бланке ответов.** *(5 баллов)*

| № | Җөмләләр | «+» яки «-» |
|---|---|---|
| 1 | Габдулла Тукай, Абдулла Алиш, Максим Горький – татар язучылары. | - |
| 2 | Сандугачлар һәм карлыгачлар көзен җылы якларга очып китәләр. | + |
| 3 | Җидене бишкә тапкырлагач, утыз җиде була. | - |
| 4 | “**Сәгать**” сүзендә 6 хәреф, 6 аваз | - |
| 5 | “**Чана**” сүзе ачык иҗекләрдән генә тора. | + |

**5. Определите корень слова.** *(4 балла)*

Сазлык – САЗ

Суыткыч – СУЫТ

Авылдаш – АВЫЛ

Кышкы – КЫШ

**6. Напишите татарские народные пословицы о Родине. (***За каждый правильный ответ по одному баллу, макс. 5 баллов)*

**7. Прочитайте текст и вставьте пропущенные окончания.** *(Максимальное количество – 8 баллов)*

**Куян баласы**

Алия дәү әнисе белән йөрергә ярата. Алар болынГА да, басуГА да гел бергә баралар. Бүген басуДА Алия куян баласы күрде. Куян баласы ни өчендер качмаДЫ. Алия тиз генә аны колакларынНАН тотып алды. Куян баласы АлияНЕҢ кулларыннан сикереп төшәргә тырышты. Ниһаять, ул арыды, тынычланды. Куян баласы йөри алмый, аның аякЛАРЫ авырта икән. «Дәваларбыз», – диде әбисе. Алар куян балаСЫН өйЛӘРЕНӘ алып кайттылар. Алия аны бүлмәГӘ җибәрде, ә ишекНЕ япты.

Берничә көнНӘН куян баласы сикерә, йөгерә, керт-керт итеп кәбестә яфраклары ашый башлады. Әй шатланды Алия!

Ә беркөнНЕ ул ялгыш ишекНЕ ачык калдырды. Йөгереп кайтты, бүлмәдән куян баласын эзли башлады – таба алмады. Кыз елап җибәрде.

– Елама, кызым, – диде әбисе. – Инде аның аяклары төзәлде. Куян баласы хәзер элеккечә йөгерә ала, ул әнисе янына урманга китте. Сиңа рәхмәт әйтте. ХайванНАР ирек яраталар бит алар.

Йомшак куян баласы әниСЕН сагынган. Алия моны аңлый иде. Ул аларНЫҢ очрашуы турында уйлады.

*(З. Гомәровадан)*

**8. Выберите наиболее подходящую для текста «Куян баласы» пословицу.** *(Максимальное количество – 5 баллов)*

☐ **Сыерчык диңгез артына китсә дә, үз туган оясына кайта.**

☐ Үз анасын зурлаган, кеше анасын хурламас.

☐ Сүзнең тозы – мәкаль.

☐ Батырлыкта матурлык.

**9. Составьте и запишите рассказ по его началу.** *(10 предложений, максимальное количество – 20 баллов)*

Марат балык тотарга бик ярата. Менә беркөнне иртән ул инешкә балык тотарга килде. Бервакыт …

______________________________________________________________________

______________________________________________________________________

______________________________________________________________________

______________________________________________________________________

______________________________________________________________________

______________________________________________________________________

______________________________________________________________________

______________________________________________________________________

______________________________________________________________________

______________________________________________________________________

**Рус телендә урта гомуми белем бирү мәктәбенең рус төркемендә укучылар өчен татар теленнән үткәрелә торган район туры өчен олимпиада биремнәренә җаваплар**
**2018-2019 уку елы, 5 нче сыйныф**

**Ответы на олимпиадные задания муниципального тура по татарскому языку для общеобразовательных организаций с обучением на русском языке**
**(для изучающих татарский язык)**
**2018-2019 учебный год, 5 класс**

*Максимальный балл – 78*

*Время выполнения – 90 минут*

**1. Продолжите сравнения.** *(Максимальное количество – 7 баллов)*

***Бүре кебек УСАЛ***

***Куян кебек КУРКАК***

***Төлке кебек ХӘЙЛӘКӘР***

***Эт кебек ТУГРЫ***

***Ишәк кебек КИРЕ***

***Фил кебек ЗУР***

***Жираф кебек ОЗЫН***

***Сүзләр: хәйләкәр, куркак, кире, усал, тугры, озын, зур.***

**2. Прочитайте текст и вставьте пропущенные окончания.**
(*Максимальное количество – 8 баллов)*

**Китапханәләр**

Китаплар эшләнә башлауга инде берничә мең ел үткән. Вавилонлылар һәм башка халыклар китапНЫ балчыкТАН ясаганнар. КытайДА беренче китапларНЫ бамбук пластинкаларГА, ә МисырДА таш плитәләргә язганнар. Урта гасырларда пергаментка язганнар һәм пергаментларНЫ дәфтәр кебек теккәннәр.

Китапларны китапханәләргә урнаштыралар. КитапханәләрНЕҢ зурлары да, кечкенәләре дә бар. Дөньяда иң зур китапханәләрнең берсе – Мәскәүдә Дәүләт китапханәСЕ. Ул берничә бинаДАН тора. БезНЕҢ илебезДӘ басылып чыкКАН һәрбер китап, һәрбер газет-журнал шушы китапханәгә килә, һәм чит илләрдән дә китап, газет, журналлар алдырыла.

Татарстанда 4 меңНӘН артык китапханә исәпләнә, ә Милли китапханә РоссияДӘ иң бай китапханәләрДӘН санала.

*(Вакытлы матбугаттан)*

---

**3. Выберите наиболее подходящую для текста «Китапханәләр»**

**пословицу.** *(Максимальное количество – 5 баллов)*

☐ Куркак кеше үз күләгәсеннән дә курка.

☐ **Китапсыз өй – тәрәзәсез өй.**

☐ Надан белмәсә дә кычкыра.

☐ Юл сорашып табыла.

**4. Напишите цифрами. (4 балла)**

Унтугыз – 19

Сиксән биш – 85

Ике йөз алтмыш җиде – 267

Өч мең биш йөз егерме биш – 3525

**5. Заполните таблицу.** *(Максимальное количество – 12 баллов)*

Салих Сәйдәшев, Муса Җәлил, Габдулла Тукай, Фәрит Яруллин, Илһам Шакиров, Сара Садыйкова, Абдулла Алиш, Бакый Урманче, Әлфия Афзалова, Харис Якупов, Роберт Миңнуллин, Шәүкәт Галиев

| **Шагыйрьләр, язучылар** | **Композиторлар** | **Җырчылар** | **Рәссамнар, сынчылар** |
|---|---|---|---|
| Муса Җәлил | Салих Сәйдәшев | Илһам Шакиров | Бакый Урманче |
| Габдулла Тукай | Фәрит Яруллин | Әлфия Афзалова | Харис Якупов |
| Абдулла Алиш | Сара Садыйкова | | |
| Роберт Миңнуллин | | | |
| Шәүкәт Галиев | | | |

**6. Определите корень слова.** *(Максимальное количество – 5 баллов)*

Тозсыз –ТОЗ

Акыллы – АКЫЛ

Шәһәрчек – ШӘҺӘР

Тотка – ТОТ

Язгы – ЯЗ

**7. Докажите, что эти слова являются омонимами (приведите примеры).** *(Максимальное количество – 12 баллов )*

Кара

1. Кара – фигыль. Мәсәлән, *Алдыңа кара!*

2. Кара – сыйфат. Мәсәлән, *Ул кара төс белән ясарга ярата.*

Атлас

1. Атлас – тукыма төре.

2. Атлас – географик термин.

Көзге

1. Көзге – исем. Мәсәлән, *Көзге каршында басып торам.*

2. Көзге – сыйфат. Мәсәлән, *Көзге көн.*

*(Мисаллар якынча бирелде.)*

**8. Напишите татарские народные пословицы о дружбе. (***За каждый правильный ответ по одному баллу, максимальное количество – 5 баллов)*

**9. Составьте и запишите рассказ по его началу.** ***(10 предложений, максимальное количество – 20 баллов)***

Көзнең матур бер көне. Данис әтисе белән урманга гөмбә җыярга килделәр. Гөмбә эзләп йөргәндә кинәт …

______________________________________________________________

______________________________________________________________

______________________________________________________________

______________________________________________________________

______________________________________________________________

______________________________________________________________

______________________________________________________________

______________________________________________________________

______________________________________________________________

______________________________________________________________

**Рус телендә урта гомуми белем бирү мәктәбенең рус төркемендә укучылар өчен татар теленнән үткәрелә торган олимпиаданың муниципаль этап биремнәренең җаваплары**
**(6 нчы сыйныф, 2018/2019 уку елы)**

*Время выполнения – 120 мин.*

*максимальный балл – 89*

**Письменная часть – 89 баллов.**

**1. Прочитайте текст, выберите наиболее подходящий для него заголовок и подчеркните его *(3 балла)***

*А. Канатлы кунак*

**2. Продолжите рассказ и напишите небольшое сочинение (*за каждое верное предложение – 3 балла, максимальный балл – 15*).**

**3. Расставьте реплики в нужном порядке (укажите последовательность в цифрах), чтобы получился диалог.**

| № | Предложения | Макс.кол-во баллов – 4 | Баллы |
|---|---|---|---|
| 3. | Мин кичә сиңа шалтыраткан идем. Әниең сине грипп белән авырый, диде. Әгәр теләсәң, мин сине табибка илтә алам. | 0,5 | |
| 6. | Рәхмәт, син чын дус! | 0,5 | |
| 1. | Сәлам, Алсу! Синең хәлләрең ничек? | 0,5 | |
| 8. | Ярый. | 0,5 | |
| 5. | Берни дә түгел. Алайса, әйдә, киттек. | 0,5 | |
| 2. | Хәзер бераз яхшырак. Соравыңа рәхмәт. | 0,5 | |
| 4. | Бик әйбәт булыр иде. Бик зур рәхмәт сиңа, Марат. | 0,5 | |
| 7. | Һәрвакыт мөрәҗәгать ит! | 0,5 | |

**4. Допишите пропущенные слова в следующих пословицах.**

| № | Предложения | Макс.кол-во баллов - 15 | Баллы |
|---|---|---|---|
| 1. | Дусны табу җиңел, саклавы АВЫР. | **3** | |
| 2. | Уйнап сөйләсәң дә, УЙЛАП сөйлә. | **3** | |
| 3. | Һөнәр ашарга сорамый, үзе АШАТА. | **3** | |
| 4. | Башланган ЭШ – беткән эш. | **3** | |
| 5. | Бер галим ЙӨЗ наданны җиңәр. | **3** | |

**5. Переведите на татарский язык и запишите.**

| № | Предложения | Макс.кол-во баллов - 16 | Баллы |
|---|---|---|---|
| 1. | Мин дустымның уңышлары белән горурланам. | **2** | |
| 2. | Бу кешеләр сезгә яхшылык телиләр. | **2** | |
| 3. | Миңа бу театрның тарихы турында кайбер мәгълүматлар кирәк. | **2** | |
| 4. | Һәр кешенең тормышында бәхетле вакыйгалар | **2** | |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | була. | | |
| 5. | Син әти-әниләрең белән Санкт-Петербургка бару турында сөйләштеңме әле? | **2** | |
| 6. | Әгәр телисез икән, мин сезгә бу мәкаләне алып киләм. | **2** | |
| 7. | Яшьләр арасында иң танылган/популяр тапшыру нинди? | **2** | |
| 8. | Ул кәгазъ бите алды һәм рәсем ясый башлады. | **2** | |

**6. Допишите окончания слов в предложениях.**

| **№** | **Предложения** | **Макс. кол-во баллов - 9** | **Баллы** |
|---|---|---|---|
| **1.** | 9 декабрь – Хәсән Туфан**ның** туган көн**е**. | **1** | |
| **2.** | Урал**да** заводта эшли, Уфа**да** укый, Урта Азия һәм Кавказ буйлап җәяүләп сәяхәт итә, гомер**енең** 16 ел**ын** сөргендә уздыра. | **2** | |
| **3.** | Татар әдәбият**ы** дәресле**генә** аның шигырь**ләре** җиңел генә эләкмәгән. | **1,5** | |
| **4.** | Аларның халык**ка** барып ирешү юл**ы** Моабит дәфтәр**ләре** тарих**ына** охшаш. | **2** | |
| **5.** | 1940 ел**ның** 18 ноябр**ендә** Хәсән Туфан**ны** кулга алалар. | **1,5** | |
| **6.** | Ул башта үлем**гә**, аннан гомерлек сөрген**гә** хөкем ителә. | **1** | |

**7. Переведите на русский язык и запишите.**

| № | **Предложения** | **Макс.кол-во баллов - 10** | **Баллы** |
|---|---|---|---|

| | | | |
|---|---|---|---|
| 1. | Завтра, 9 декабря, ночью и днем на территории Татарстана местами опустится туман. | **2** | |
| 2. | Пожелайте спокойной ночи своим родителям. | **2** | |
| 3. | Каждый должен знать свои корни. | **2** | |
| 4. | Вспомните стихотворение Габдуллы Тукая «Родной язык». | **2** | |
| 5. | Некоторые ласточки улетают в Восточную и Южную Африку. | **2** | |

**8. Прочитайте текст и вставьте нужные слова (*максимальное количество баллов – 13*).**

Имбир – ***мәңге*** яшел тропик үсемлек. Дәвалау ***өчен*** имбирнең чи тамыры ***яисә*** киптереп вак итеп төелгән тамырының порошогы кулланыла. Имбирне борынгы заманнардан ***бирле*** үстерәләр. Хәзер Кытай, Корея, Малазия, Индия аны ***күп*** күләмдә җитештерә.

Имбир – ачы ***һәм*** хуш исле тәмләткеч, шул ук вакытта ***бик*** нәтиҗәле дәвалау чарасы да. Үсемлекнең вакланган чи тамырын су парында тотып куу ысулы ***ярдәмендә*** эфир мае ясала. Ул ислемай, косметик әйберләр эшләп чыгаруда ***киң*** кулланыла.

Имбир Якын Көнчыгыш кухнясында бик популяр, ***аны*** иттән, яшелчәләрдән, оннан хәзерләнгән ризыкларга һәм, шулай ук, төрле эчемлекләргә кушалар.

Имбир составындагы бик күп биологик актив матдәләр организмны тукландыралар, ашаган ризыкны эшкәртүне һәм үзләштерүне яхшырталар, ***чөнки*** имбирдә ашказаны, эчәкләрнең, ашказаны асты бизенең эшчәнлеген стимуллаштыра ***торган*** матдәләр бар. Шул сәбәпле, имбир тамыры ашкайнату әгъзалары авыруы ***вакытында*** нәтиҗәле дәвалау чарасы булып тора.

**9. Установите соответствие между словом и его лексическим значением** (***максимальное количество баллов – 4***).

| А | Ә | Б | В |
|---|---|---|---|
| **3** | **1** | **4** | **2** |

**Рус телендә урта гомуми белем бирү мәктәбенең рус төркемендә укучылар өчен татар теленнән үткәрелә торган муниципаль олимпиада биремнәренең җаваплары**
**(7 нче сыйныф, 2018/2019 уку елы)**

*Время выполнения – 120 мин.*
*максимальный балл – 107*

**Устная часть (20 баллов)**
Составьте рассказ о рабочих профессиях (5 – 7 предложений).

**Письменная часть (87 баллов)**

**1. Прочитайте текст. Ответьте на следующие вопросы.**

| № | **Ответы** | **Макс.кол-во баллов - 11** | **Баллы** |
|---|---|---|---|
| 1. | *Текст кырмыска(лар) турында.* | 3 | |
| 2. | *Кырмыскаларны яңгыр суалчаннары (урман санитарлары) белән чагыштыралар.* | 1 | |
| 3. | *Алар урманны чистарту эшендә катнашалар.* | 1 | |
| 4. | *Кырмыска ояларын тузгыту табигатькә зыян сала.* | 1 | |
| 5. | *Урманда үзеңне дөрес тотарга кирәк. Урманда кырмыска ояларын тузгытырга ярамый. Урманда кычкырып сөйләшергә ярамый. Урманда учак ягарга ярамый. Урманда кош-корт, җәнлекләргә зыян салырга ярамый.* | 5 | |

**2. Переведите на русский язык и запишите.**

| № | Предложения | Макс.кол-во баллов – 10 | Баллы |
|---|---|---|---|
| 1. | *Пусть войдет свежий воздух, для этого необходимо открыть окна.* | 2 | |
| 2. | *Несмотря на то, что взошло солнце, не потеплело.* | 2 | |
| 3. | *Чем больше будешь стараться, столько же тебе хорошо.* | 2 | |
| 4. | *Её отец – руководитель торговой фирмы.* | 2 | |
| 5. | *Ребята обещали помочь птицам и сдержали свое слово.* | 2 | |

**3. Допишите окончания слов в предложениях.**

| № | Предложения | Макс. кол-во балло в - 9 | Баллы |
|---|---|---|---|
| 1. | Тоткынлык ел**лары** – Хәсән Туфан иҗат**ының** иң югары нокта**сына** җиткән еллар. | 1,5 | |
| 2. | Ә колония**дә** шигырь язу өчен кәгазь булмый. | 0,5 | |
| 3. | Хәсән Туфан шигырь**ләрен** башта фәкать күңел**енә** беркетеп, исендә тота. | 1 | |
| 4. | Ләкин күбрәк языла башлау белән алар**ны** хәтердә тоту авырлаша. | 0,5 | |
| 5. | Шагыйрь ул вакытта металлургия завод**ында** кайнар цех**та** эшли. | 1 | |
| 6. | Күбесенчә үз теләг**е** белән төнге смена**га** йөри. | 1 | |
| 7. | Ә Хәсән абый, иптәш**ләренең** күзлек**ләрен** җыя да, өч-дүрт кат итеп киеп, каты карандаш**ны** кыл | 2,5 | |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | очы сыман очлап, шигырь**<u>ләрен</u>** папирос кәгаз**<u>енә</u>** яза. | | |
| 8. | Биш бармак яссылы**<u>гында</u>** кәгазь кисә**<u>генә</u>** Хәсән абый 300 юллык шигырь сыйдыра. | 1 | |

**4. Допишите пропущенные слова в следующих пословицах.**

| № | | Макс. кол-во баллов - 10 | Баллы |
|---|---|---|---|
| 1. | Адашкан кешедән ЮЛ сорамыйлар. | 2 | |
| 2. | Тыйнакның кулы эшләр, МАКТАНЧЫКНЫҢ теле эшләр. | 2 | |
| 3. | Әйбернең яңасы яхшы, дусның ИСКЕСЕ яхшы. | 2 | |
| 4. | Сүздә мактанма, ЭШТӘ мактан. | 2 | |
| 5. | Миң дус аз, БЕР дошман күп. | 2 | |

**5. Прочитайте текст и вставьте нужные слова (*максимальное количество баллов – 16*).**

| |
|---|
| Билгеле булганча, 2019 елда Казанда WorldSkills һөнәри осталык ***<u>буенча</u>*** дөнья чемпионаты узачак. Әлеге ***<u>мөһим</u>*** чарага әзерлек күптән бара инде. Һәр мөһим ярышларның ***<u>үз</u>*** талисманы була. WorldSkills Kazan 2019 талисманнары да ***<u>билгеле</u>*** булды. <br> Татарстан Президенты Рөстәм Миңнеханов һәм милли уеннарда катнашу ***<u>өчен</u>*** җыелган тамашачылар Алмаз, Алтын ***<u>исемле</u>*** талисманнарны беренче булып күрделәр. 2019 елда Казанда узачак WorldSkills дөнья чемпионатының ***<u>төп</u>*** йөзләре – Алмаз һәм Алтын булачак. Әлеге уйлап чыгарылган персонажлар үз сәләтләре аркасында бөтен өлкәләрдә ***<u>дә</u>*** уңышка ирешүне күздә тота. Алар – чемпионатта катнашучыларның ***<u>җыелма</u>*** образы. <br> Оештыручылар, чара Казанда узгач, талисманнар ***<u>аша</u>*** чемпионатның |

| |
|---|
| милли төсмергә ия булуын да телиләр. “Алмаз” ***һәм*** “Алтын” исемнәре күнекмәләрнең камил булуын күрсәтә. Чөнки алмаз ***белән*** алтын – дөньядагы ***иң*** кыйммәтле материаллар. Җитмәсә, чемпионатта “Зәркән эше” ***дигән*** компетенция дә бар.<br>Кызыксынучанлык, эш сөючәнлек, акыл – талисманнарның төп сыйфатлары. Талисманнарның үз легендасы бар: алар ***барлык*** авырлыкларны да ***тиз*** җиңеп чыга. |

**6. Переведите на татарский язык и запишите.**

| № | Предложения | Макс.кол-во баллов - 12 | Баллы |
|---|---|---|---|
| 1. | Гафу итегез, миңа сәгать кирәк, кемгә мөрәҗәгать итәргә мөмкин? | 2 | |
| 2. | Зинхар өчен, миңа ничек итеп Заманча сәнгать галериясенә барып булганын аңлатыгыз әле. | 2 | |
| 3. | Ноябрь буе һава торышы яхшы торды. | 2 | |
| 4. | Бүген аяз кояшлы һава торышы булды, ә иртәгә кар көтелә. | 2 | |
| 5. | Бу – иң авыр сорауларның берсе. | 2 | |
| 6. | Без бер йортта торсак та, мин аны бик сирәк күрәм. | 2 | |

**7. Прочитайте текст. Посмотрите внимательно на каждую строку: некоторые строчки правильные, а в некоторых строках есть ошибки. Если считаете, что все верно, в правый столбик поставьте плюсик, неверно – укажите ошибку (максимальный балл – 9, за каждое верное совпадение по баллу).**

| | **Умартачылык** | |
|---|---|---|
| | Бал борынгы заманнарда ук дәвәлау максатында | **дәвәлау** |
| | файдаланылган. Борынгы Грециянең атаклы математигы | + |

| | | |
|---|---|---|
| **1.** | Пифагор үзенең озын гөмерле булуын бал ашаудан күргән. | гөмерле |
| **2.** | Атаклы табип, шагыйрь Абугалисина: «Әгәр яшьлегеңне | табип |
| **3.** | сакларга теләсәң, бал аша», – дигән. Соңгы арада умартачылык | + |
| **4.** | продуктлары фәнни нигездә өйрәнелә, моның өчен | өчен |
| **5.** | продуктларның химик составы, аларның сәламәт һәм авыру | + |
| **6.** | кеше организмына тәйсир итү көче тикшерелә. Хәзерге | тәйсир |
| **7.** | вакытта дәвалау препаратлары – бал, корт агуы, корт ана сөте | + |
| **8.** | катнашкан препаратлар алу технологиясе эшләнде. | + |
| **9.** | Бал составында 60 ка якын мәтдә бар. | мәтдә |

**8. По описанию найдите и напишите название предмета.**

| № | **Предложения** | **Макс.кол-во баллов - 6** | **Баллы** |
|---|---|---|---|
| 1. | **УҢЫШ** – иген, җиләк-җимеш, яшелчәләрнең җыелган күләме. | 1 | |
| 2. | **ОЧРАШУ** – берәр максат белән, кемнең дә булса килү уңае белән вакытлыча бергә булу, җыелу. | 1 | |
| 3. | **СӘГАТЬ** – тәүлек эчендә вакытны үлчәү әсбабы. | 1 | |
| 4. | **ТУКТАЛЫШ** – пассажирлар транспортка утыру яки төшү өчен билгеләнгән урын. | 1 | |
| 5. | **ЯШЕЛ**– спектрда төп төсләрнең берсе – зәңгәр белән сары арасындагы төс. | 1 | |
| 6. | **БАТЫР** – куркусыз, кыю, уңган, булган кеше, баһадир. | 1 | |

**9. Установите соответствие между словом и его лексическим значением (*максимальное количество баллов – 4*).**

| | |
|---|---|
| **А.** Сәнгать<br>**Ә.** Мәдәният<br>**Б.** Икътисад<br>**В.** Сәнәгать | **1.** Кешеләрнең җәмгыятькә һәм бүтән кешеләргә карата мөнәсәбәтләре.<br>**2.** Хуҗалык төзелеше, тормышы.<br>**3.** Культура.<br>**4.** Дөньяны эстетик танып белү.<br>**5.** Чимал эшкәртү. |

| А | Ә | Б | В |
|---|---|---|---|
| 4 | 3 | 2 | 5 |

**Рус телендә гомуми белем бирү оешмаларының рус төркемнәрендә белем алучы укучылар өчен татар теленнән муниципаль тур олимпиада биремнәре җаваплары**

**8 нче сыйныф**

*Максимальный балл – 91*

*Время выполнения – 120 минут*

**Устная часть**

**Озаглавьте и опишите рисунок. 25 баллов**



**Письменная часть.**

**1. Переведите текст на татарский язык и запишите в строке после каждого предложения. 14 баллов**

| № | Предложения | Макс. кол-во баллов за правильный ответ – 14 баллов | Баллы |
|---|---|---|---|
| 1. | Коля заболел. Сейчас он лежит в больнице. | 2 | |
| | *Коля авырды. Хәзер ул хастаханәдә ята.* | | |
| 2. | Никто к нему в гости не приходил. Могли заразиться. | 2 | |
| | *Аңа кунакка беркем дә килми. Үзләре авырырга мөмкин иде.* | | |
| 3. | Лежит Коля, глядит в окно. А с третьего этажа можно увидеть только небо. | 2 | |
| | *Коля ята, тәрәзәгә карый. Өченче каттан күкне генә күреп була.* | | |
| 4. | Вдруг Коля увидел в окне красный шар. | 2 | |
| | *Кинәт Коля тәрәзәдә кызыл шар күрде.* | | |
| 5. | Шар поднимается к окну и двигается вверх и вниз. | 2 | |
| | *Шар тәрәзәгә менә һәм аска, өскә хәрәкәтләнә.* | | |
| 6 | Коля внимательно посмотрел. На шарике нарисовано смешное лицо. | 2 | |
| | *Коля игътибар белән карады. Шарда кызык кеше йөзе ясалган иде.* | | |
| 7. | Стало Коле хорошо. Это пришли его друзья. Они помнят о Коле. | 2 | |
| | *Коляга рәхәт булып китте. Аның дуслары килгән. Алар Коля турында хәтерлиләр.* | | |

**2. Сезнең авыру иптәшегезнең хәлен белгәнегез бармы? Шул турыда языгыз (10 баллов. 1 балл за каждое правильное предложение).**

**3. Подберите и допишите пропущенные слова в пословицах. 7 баллов**

| № | Предложения | Слова | Макс. кол-во баллов за правиль-ный ответ – 7 | Баллы |
|---|---|---|---|---|

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| 1 | Дөньяда иң кечкенә бәхет – байлык, иң зур бәхет – *саулык*. | байлык | 1 | |
| 2 | *Матурлык* – сәламәтлек билгесе. | мал | 1 | |
| 3 | Сау кешегә көн дә *бәйрәм*. | бәйрәм | 1 | |
| 4 | *Байлык* – бер айлык, саулык – гомерлек. | саулык | 1 | |
| 5 | Баш сау булса, башка *бүрек* табылыр. | карават | 1 | |
| 6 | Авыруга алтын *карават* та ярдәм итми. | бүрек | 1 | |
| 7 | Баш сау булмаса, *мал* күзгә күренми. | матурлык | 1 | |

**4. Составьте предложения с словосочетаниями. 10 баллов**
*Башка кию, баш бармак, баш хәреф, баш ию, баш күккә тию.*

| **№** | **Предложения** | Макс. кол-во баллов за правильный ответ – 10 | Баллы |
|---|---|---|---|
| 1. | Салкында башка башлык киям. | 2 | |
| 2. | Баш бармак – бабай, ... | 2 | |
| 3. | Яңа җөмлә баш хәрефтән языла. | 2 | |
| 4. | Талант алдында баш иям. | 2 | |
| 5. | Шатлыктан башым күккә тия. | 2 | |

**5. Расставьте ударения в словах. 15 баллов**

*ТрАкторчы, открЫткалар, Уйнагыз, уйнасыннАр, Утыр, утырсЫн, сикЕрмә, бИрми, бАшкала, нИчә? мОндый, Ягъни, Иң матур, Ямь-яшел, бЕз дә.*

**6. Прочитайте текст. Ответьте на вопросы и запишите в строке после каждого предложения. 10 баллов**

Сохранить здоровье не просто, а потерять можно сразу. Сберечь его поможет спорт! Физические упражнения укрепляют мускулатуру, сердце, позволяют оставаться стройными, избавляют нас от многих болезней.

Великий философ говорил о пользе занятий спортом: «Гимнастика удлиняет молодость человека».

Здоровье – это красота! Об этом люди знали еще в Древнем Китае и Индии, в Древней Греции. Здоровый человек всегда хорошо выглядит.

А.С.Пушкин был крепкого телосложения, мускулистый, гибкий, благодаря ежедневной гимнастике. Л.Н.Толстой прожил долгую жизнь

благодаря физическим упражнениям. Он увлекался ездой на велосипеде, на лошади. В 82 года он за день совершал верхом дальние прогулки.

| № | **Предложения** | Макс. кол-во баллов за правильный ответ – 10 баллов | Баллы |
|---|---|---|---|
| 1. | Сәламәтлекне сакларга нәрсә ярдәм итә? | 2 | |
| | *Сәламәтлекне сакларга спорт ярдәм итә.* | | |
| 2. | Физик күнегүләрнең нинди файдасы бар? | 2 | |
| | *Физик күнегүләр мускулатураны, йөрәкне ныгыта, төз булып калырга ярдәм итә, күп чирләрдән арындыра.* | | |
| 3. | Бөек философ спортның файдасы турында нәрсә әйткән? | 2 | |
| | *Гимнастика яшьлекне озынайта.* | | |
| 4. | “Сәламәтлек – матурлык” дигән фикер белән килешәсезме? | 2 | |
| | *Сәламәт кеше һәрвакыт матур була.* | | |
| 5. | А.С.Пушкин һәм Л.Н.Толстой ни өчен сәламәт булганнар? | 2 | |
| | *А.С.Пушкин һәм Л.Н.Толстой физик күнегүләр белән шөгыльләнгәннәр.* | | |

**Рус телендә гомуми белем бирү оешмаларының рус төркемнәрендә белем алучы укучылар өчен татар теленнән муниципаль тур олимпиада биремнәренә җаваплар**

**9 нчы сыйныф**

*Максимальный балл – 96*

*Время выполнения – 180 минут*

**Устная часть**

**Озаглавьте рисунок. Охарактеризуйте представителя каждой профессии. 25 баллов**



**Письменная часть**

**1. Переведите текст на русский язык и запишите в строке после каждого предложения. 12 баллов**

| № | Предложения | Макс. кол-во баллов за правильный ответ – 12 баллов | Баллы |
|---|---|---|---|
| 1. | Дәүләтнең бюджеты булган кебек, һәр гаиләнең дә бюджеты була.<br>*Как и у государства, у каждой семьи бывает бюджет.* | 2 | |
| 2. | Ул акчаны дөрес тотарга ярдәм итә.<br>*Это позволяет правильно расходовать деньги.* | 2 | |
| 3. | Сезгә, булачак гаилә башлыкларына һәм хуҗабикәләргә, гаилә бюджетын төзергә өйрәнергә кирәк.<br>*Вам, будущим главам семьи и домохозяйкам, надо научиться составлять семейный бюджет.* | 2 | |
| 4. | Ул керемнәр һәм чыгымнардан тора.<br>*Он состоит из доходов и расходов.* | 2 | |
| 5. | Керемгә хезмәт хакы, пенсия, пособие, эшмәкәрлек табышы керә.<br>*В доход входят заработная плата, пенсия, пособие, предпринимательский доход.* | 2 | |
| 6 | Чыгымнарга салымнар, газ, ут, страхование өчен түләүләр, азык-төлек, кием-салым, мәгариф, мәдәнияткә тотылган чыгымнар керә.<br>*В расход входят налоги, плата за газ, свет, страхование, расходы на питание, одежду, образование, культуру.* | 2 | |

2. **Запишите пропущенные реплики в диалогах. 14 баллов**

| № | Реплики | Макс. кол-во баллов за правильный ответ – | Баллы |
|---|---|---|---|

| | | 14 | |
|---|---|---|---|
| 1. | - Казан шәһәре кайда урнашкан?<br>- Иделнең сул як ярына урнашкан. | 2 | |
| 2. | - Казанда ничә кеше яши?<br>- 1 миллионнан артык кеше яши. | 2 | |
| 3. | - Казанда ничә район бар?<br>- Шәһәр җиде районга бүленгән. | 2 | |
| 4. | - Казанның иң истәлекле урыны нәрсә?<br>- Казанның иң истәлекле урыны – Кремль. | 2 | |
| 5. | - Казан Кремле эчендә нәрсәләр бар?<br>- Анда Президент сарае, Сөембикә манарасы, Благовещение соборы урнашкан. | 2 | |
| 6. | - Кремль каршында нинди һәйкәл бар?<br>- Кремль каршында Муса Җәлил һәйкәле бар. | 2 | |
| 7. | - Казанда иң яраткан урының нинди?<br>- Мин Казанда циркта булырга яратам. | 2 | |

**3. Распределите следующие слова по группам. 5 баллов**

Сатучы, шофер, икътисадчы, трамвай йөртүче, агроном, тракторчы, укытучы, биюче, тәрбияче, зоотехник, фәнни хезмәткәр, рәссам, архитектор, троллейбус йөртүче, игенче, елгачы, скульптор (сынчы), сыер савучы, машинист, диңгезче.

**1)** Сәүдә һәм икътисадка бәйле һөнәрләр: сатучы, икътисадчы.
2) Транспортка бәйле һөнәрләр: шофер, трамвай йөртүче, троллейбус йөртүче, елгачы, машинист, диңгезче.
3) Авыл хуҗалыгына бәйле һөнәрләр: агроном, тракторчы, зоотехник, игенче, сыер савучы.
4) Мәгърифәткә бәйле һөнәрләр: укытучы, тәрбияче, фәнни хезмәткәр.
5) Сәнгатькә бәйле һөнәрләр: биюче, рәссам, архитектор, скульптор (сынчы).

**4. Составьте предложения с словосочетаниями. 10 баллов**

Һөнәр сайлау, җаваплы вазифа, максатка ирешү, киңәш бирү, эшкә урнашу.

| **№** | **Предложения** | Макс. кол-во баллов за правильный ответ – 10 | Баллы |
|---|---|---|---|
| 1. | *Һәр югары сыйныф укучысы яхшы һөнәр сайлау турында уйлана.* | 2 | |
| 2. | *Шәфкать туташы булу – җаваплы вазифа.* | 2 | |

| | | | |
|---|---|---|---|
| 3. | *Максатка ирешү өчен тырышып эшләргә кирәк.* | 2 | |
| 4. | *Акыллы кешеләрдән киңәш сорадым.* | 2 | |
| 5. | *Эшкә урнашу өчен тәҗрибә таләп ителә.* | 2 | |

**5. Определите правильное написание собственных имени напишите в таблице. 10 баллов**

| № | Собственные имена | Правильное написание собственных имен | Макс. кол-во баллов за правильный ответ – 10 | Баллы |
|---|---|---|---|---|
| 1. | (Т, т)атарстан (Р, р)еспубликасы | Татарстан Республикасы | 1 | |
| 2. | (К, к)азан (Д, д)әүләт (У, у)ниверситеты | Казан дәүләт университеты | 1 | |
| 3. | (Җ, җ)иңү (К, к)өне | Җиңү көне | 1 | |
| 4. | (Х, х)алыкара (Х, х)атын-кызлар (К, к)өне | Халыкара хатын-кызлар көне | 1 | |
| 5. | (М, м)инистрлар (С, с)оветы (Р,р)әисе | Министрлар Советы рәисе | 1 | |
| 6. | (Д, д)әүләт (Д, д)умасы | Дәүләт Думасы | 1 | |
| 7. | (Р, р)оссия (Ф, ф)едерациясе (П, п)резиденты | Россия Федерациясе Президенты | 1 | |
| 8. | (С, с)аратов (Ө, ө)лкәсе | Саратов өлкәсе | 1 | |
| 9. | (И, и)дел (Е, е)лгасы | Идел елгасы | 1 | |
| 10 | (Г, г)алиаскәр (К, к)амал (И, и)семендәге (Т, т)атар (Д, д)әүләт ( А, а)кадемия (Т, т)еатры | Галиаскәр Камал исемендәге Татар дәүләт академия театры | 1 | |

**6. Напишите рассказ о самом любимом месте в родном городе. (10 предложений). 20 баллов**

**Рус телендә белем бирү мәктәбенең рус телле укучылары өчен татар теленнән үткәрелә торган олимпиаданың муниципаль тур биремнәренең җаваплары**
**10 нчы сыйныф, 2018/2019 уку елы**

*Максимальный балл –* ***149***

*Время выполнения – 180 минут*

**1. Озаглавьте картину. Составьте рассказ и расскажите (12-15 предложений) – макс. кол во баллов (2+30=32)**

**Бөек Казан ханлыгының Ханбикәсе .**

**Ханбикә Сөембикә улы белән һ.б.**

***Бу – танылган рәссам Рушан Шәмсетдиновның Сөембикә ханбикә һәм аның улы Үтәмешгәрәйгә багышланган картинасы. Казан ханлыгының тарихын Сөембикә исеменнән башка күз алдына да китереп булмый. Ул – Казан ханлыгының беренче ханбикәсе. Сөембикә ире Сафагәрәй үлгәннән соң, Казан ханлыгы белән идарә итүне үз өстенә ала. Казан ханлыгы өчен иң авыр чорда ханлыкны саклап калу өчен көрәшә. Ләкин Казан ханлыгы җимерелә. Шуннан соң Сөембикәне һәм улы Үтәмешгәрәйне Мәскәүгә җибәрәләр. Казанда аның исеме белән бәйле истәлекле урыннар күп. Казан Кремлендә Сөембикә манарасы бар...***

*(Текст үрнәк буларак китерелми, якынча шушындыйрак булырга мөмкин)*

II часть.

2. **Прочитайте текст** (за все задания макс. – 18 б.).

**2.1.Разделите на смысловые части и озаглавьте каждую часть** (макс. – 10б.).

1) Урманга килү.
2) Урмандагы гүзәллек.
3) Гөлнара табигатьне аңлый белә.
4) Урманны пычратып калдырырга ярамый.
...

**2.2. Подберите и напишите синонимы выделенных слов** (1 б. за каждое слово, макс. – 4 б.)
Шулчак//шулвакыт//шунда
Хатирәләр//истәлекләр
...
**2.3. Найдите и выпишите из текста слова, выражающие просьбу** ( макс. – 4 б.).
Рөхсәт сорау
керергә мөмкинме
мөмкин булса
сайрачы

**3. Напишите 12 – 15 предложений, как ответ на вопрос из текста “Ә без?”** (макс. – 30 б.)

...

**4. Переведите на русский язык и запишите** (макс. – 6 б.).

1) В Великой Отечественной войне участвовали не только люди, но и собаки. 2) Собаки были хорошими связистами. 3) Например, собака по кличке Джек передал(а) около 3 тысяч сообщений. 4) “Рядовой” Дик на Ленинградском фронте поставил рекорд. 5) Собаки участвовали в разминировании 303 городов. 6) Они выводили тысячи раненных солдат из поля боя.

**5. Допишите пропущенные слова в следующих пословицах** (макс. – 5 б.).

1. Акыллы өйрәнер, ахмак өйрәтер.
2. Туры сүз таш кисә.
3. Эзләмичә энә дә табылмас.
4. Һәр эш җае белән, ботка пешә мае белән.
5. Иясен//хуҗасын сыйласаң, этенә сөяк сал.

**6. Переведите на татарский язык и запишите** (макс. – 6 б.).

1) Үсемлекләрнең һәм хайваннарның кайберләре Кызыл китапка кертелгән.

2) Табигатенең байлыгы һәм пейзажының матурлыгы буенча Татарстан Европаның күп кенә илләре белән ярыша ала.

3) Табигать ул – вазадагы чәчәкләр, сандугач сайравы, кояшлы пляжлар һәм җылы яңгыр, яхшы кәеф.

4) Табигатьне яратыгыз, аны саклагыз һәм ул сезгә рәхмәтле булыр.

5) Табигатьне саклау – ул Җирдәге яшәешне саклау.

6) Ул кешене тәрбияләүдә һәм аның сәламәтлеген саклауда бик зур роль уйный.

**7. Допишите пропущенные части диалога** (макс. – 8 б.).

- Син бүген бигрәк матур, бәйрәмчә киенгәнсең?
- Мин яңа күлмәгемне кидем, чөнки бүген минем туган көнем. Аны миңа әнием текте.

- Ул тегүчеме әллә?

- Ул – фотограф.

- Син аның фотога төшергәнен күргәнең бармы?

- Юк, минем аның фотоларын күргәзмәдә генә күргәнем бар.

- Син туган көнеңә күлмәк бүләк итүләрен теләгән идеңме?

- Әйе, нәкъ менә шундый күлмәк теләгән идем. Тагын компьютер.

- Бүләк иттеләрме соң?

- Әтием бүләк итте. Ул – чын язучы.

- Чын язучы нинди була да чын булмаган язучы нинди була?

- Чын язучылар яхшы китаплар яза, ә чын булмаганнар – җыен чүп-чар.

- Син нинди китаплар укырга яратасың?

- Мин феялар турында укырга яратам.

- Син Фея булырга телисеңме?

- Әйе. Әле тагын Кар кызы буласым килә.

**8. Прочитайте стихотворение, найдите и выпишите глаголы в отрицательной форме, переведите** (макс. –14 б.).

“Не бери”, “не говори”.
“Не дерись”, “не обзывайся”,
“Не перечь”, “не отвлекайся”,
“Не царапай”, не кори”...

Это кто такой ученый,
Умный, строгий и прямой
Ребятишек увлеченно
Учит словно заводной:
“Ты не бегай”, “ты не прыгай”,
“Ты не лазай”, “ты сиди”,
Да “не трогай”, да “не двигай”,
Да “волчок не заводи”...
Это мальчик наш Василий,
Двух малюток старший брат.
Мама с папой поручили,
Уходя ему ребят.
Из-за строгости братишки

Малыши сидят. Как мышки.
Строгость в меру хороша,
Меру знай, моя душа. (Татьяна Дашкевич)

Не бери – алма, не говори – әйтмә, не дерись – сугышма, не обзывайся – үртәмә//атама, не перечь – каршы әйтмә//киреләнмә, не отвлекайся – бүленмә//читкә китмә, не царапай – тырнама, не кори – шелтәләмә//ачуланма, не бегай – йөгермә, не прыгай – сикермә, не лазай – менмә, не трогай – тимә, не двигай – селкетмә//күчермә, не заводи – эшләтмә//кабызма

**9. Прочитайте предложения, верните слова, образовав нужную форму, в текст (**макс. – 10б.).

| | |
|---|---|
| Бездә кышлаучы кошларны суыклар куркытмый, ә менә ачлык – аларның иң явыз дошманы. Менә шуңа күрә дә без кошлар турында даими кайгыртырга, җимлекләр ясап элергә тиеш булабыз. Җимлекне бакчага элеп куйганда, кошлар агачларда булган зарарлы бөҗәкләрне дә чүплиләр. Җимлекләрне төрлечә эшләргә мөмкин. | кышлау<br>ач<br>җим<br>зарар<br>төрле |

**10. Напишите комментарий соревнования Вашего любимого вида спорта для телезрителей** (8-10 предл., макс. – 20 б.).

Хәерле кич, хөрмәтле телевизор караучылар. Без бүген сезнең белән “Казан-Арена” спорт сараенда бара торган ... ярышны карыйбыз. ...

**Рус телендә белем бирү мәктәбенең рус телле укучылары өчен татар теленнән үткәрелә торган олимпиаданың муниципаль тур биремнәренең ачкычы**
**11 нче сыйныф, 2018/2019 уку елы**

*Максимальный балл – **156***

*Время выполнения – 180 минут*

**I. Устная часть (32 б.)**

**1). Озаглавьте картину (2 б.). Составьте небольшой рассказ по картине (12-15 предл. – макс. – 30 б.).**

**1. Бөек Болгар дәүләте**

**2. Илчеләр каршылау**

Бу картинаны танылган татар рәссамы Рушан Шәмсетдинов ясаган. Картина Бөек Болгар дәүләтенә багышланган. ...

**II.**

2. **Прочитайте. О героизме и творчестве какого татарского поэта или писателя вы знаете? Напишите об этом** (12-15 предл., макс. – 30 б.)

Татарстан Язучылар союзының вестибюленә мәрмәр такта куелган. Ул тактада Бөек Ватан сугышында үлеп калган утыз язучының фамилиясе язылган. Алар язасы әсәрләрен язып бетермичә, яшәргә өлгермичә үлгәннәр.

Польша җирендәге Згеж дигән кечкенә генә шәһәрдә Гадел Кутуй күмелгән. “Тапшырылмаган хатлар” авторы Фатих Кәрим җиңүгә ике ай кала Кенисберг янында һәлак була. Дахауның крематорий мичләрендә фашистлар Совет Армиясе полковнигы шагыйрь Хәйретдин Мөҗәйне яндырдылар. Бу исемлектә җырлары бөтен планетага таралган легендар Муса Җәлил, аның көрәштәше Абдулла Алиш та бар.

*Минем танылган татар шагыйре, татар халкының батыр улы Муса Җәлил турында язасым килә. ...*

3. **Переведите на русский язык и запишите** (макс. – 6 б.).

(1) Время быстро проходит. (2) Говорят, что невозможно проследить за течением времени. (3) Неправда. (4) Время за собой оставляет каменные дворцы, цветущие сады, новые электростанции, дремучие леса. (5) Время предстает перед нами в виде построенных новых городов, написанных новых произведений, открытых новых звезд. (6) Время торопит людей.

**4. Переведите на татарский язык и запиши. (5 б.)**

1. Бу хәл Казанда яшьләр фестивале уздырылган көннәрдә булды. 2. Минем яныма бер кыз килде һәм, татарча әйтелешләрен бозып, аерым сүзләр әйтә

башлады. 3. Сүзләрнең мәгънәләрен аңлыйм, ләкин кызның нәрсә белергә теләвен һич кенә дә аңлый алмадым. 4.Мин аны аңлый алмадым, чөнки ул аерым сүзләрне ятлаган, ә грамматиканы белми иде. 5**.** Ә сүзләрне үзара бәйләргә кирәк иде.

**5. Напишите диалог со своим одноклассником на тему: “Нужно ли знать грамматику изучаемого языка?”( макс. – 20 б.)**

- *Мин татар телен өйрәнә башладым. Киләчәктә миңа татар телен белү кирәк булачак.*

- *Шулаймыни? Нинди дәреслек буенча өйрәнәсең?*

- *Дәреслек буенча түгел, сүзлек буенча өйрәнәм. Мин сүзләр ятлыйм.*

- *Сүзләр ятлап кына татарча сөйләшеп булмас, дип уйлыйм мин.*

- ...

**6. Найдите лишние слова, выпишите, переведите (4 б.). С выделенными словами составьте предложения (4 б.) – (макс. – 8 б.).**

1) бозлы, бозык, **бозлана**

2) **очлы**, очла, очкын

3) язгы, **язмача**, язулы

4) чәчле, чәчкеч, **чәчүлек**

*Бозык – испорченный, очкын – искра, язгы – весенний, чәчле – имеющий (ая)волосы*

*Салкын көннәрдә тәрәзә пыяласы бозлана. ...*

**7. Найдите слова, спрятанные в следующих словах (макс. – 10 б.):**

умыртка, юмартлык

*умыртка*: *ук, ука, урт, урак, урам, утар, март, кыр...*

*юмартлык: март, арт, юл, тар, лар...*

**8. Прочитайте, напишите ответ (макс. – 5 б.)**

Роза, Нина, Наза, Әсма бер малай белән танышалар. Үзләренең исемнәрен әйтәләр дә:

- Синең исемең ничек соң? – дип сорыйлар.
- Берегезнең исеменнән беренче хәрефне, икенчегезнең исеменнән икенче хәрефне, өченчегезнең исеменнән өченче хәрефне, дүртенчегезнең

исеменнән дүртенче хәрефне алып, бергә тезгәч, минем исемем килеп чыга, – дигән малай.

Малайның исеме ничек булган?

*Риза*

**9. Восстановите стихотворение, допишите пропущенные слова** (по 2 б. = 24 б.)

Ап-ак тау *өстендә*
Ап-ак кар *ява.*
Ап-ак яр *буеннан*
Ап-ак юл *ярам.*
Ак тунлы *агачлар*
Ак бүрек *кигән*.

Ак шәлен *ябынып*,
Ап-ак кыш *килгән* .
Ак мамык *бияләй*,
Ак баулы *чанам*.
Ак кардай *уйнаклап*,
Ак тауга *чабам*.

(Р.Вәлиева)

**10. Напишите подходящие реплики (по 1 б = 4 б.).**

1) Спроси у учителя о том, когда он(а) объявит результаты самостоятельной работы.

- ..., *Сез мөстәкыйль эшнең нәтиҗәләрен безгә кайчан әйтәсез?*

2) Сообщи другу (подруге), если в выходные погода будет хорошая, то вы всей семьей пойдете на каток.

- *Ял көннәрендә һава торышы яхшы булса, без гаиләбез белән шугалакка барачакбыз.*

3) Сообщи маме о том, что ты стал(а) победителем международной олимпиады.

- *Әнием, мин халыкара олимпиада җиңүчесе булдым.*

4) Предложи сестре сходить вместе на премьеру нового фильма.

- *Апам, әйдә, бергәләп, яңа фильм премьерасына барабыз.*

**11. Придумайте и напишите пропущенную часть текста** (5 – 6 предл., по 2 б = 12 б.)

Минем исемем Бак. Мин хәзер аспирант. Ун ел элек мин Ханойда бер кыз белән таныштым. Ул вакытта миңа 17 яшь – мин 10 нчы класста укый идем. Ул кыз исә – 8 нче класста. Без китапханәдә таныштык.

*Китапханәдән без бергә чыктык. Кич матур, җылы иде. Без шактый озак урамда сөйләшеп йөрдек...* ........................................................................ ........................................................................................................................ ........................................................................................................................ ........................................................................................................................ ....................................................................................................................

Мин дә лекцияләр тәмамлангач, китапханәгә йөгерәм. Аны көтәм. Килсен генә. Ул килгәч, без коридорда озак сөйләшеп утырабыз. Аннан соң урамга чыгабыз, паркта йөрибез, кафега керәбез, мороженое (туңдырма) ашыйбыз. Ул шоколадлы мороженое бик ярата иде.